Сәймә Фәттах кызы Алыкова (Әхмәтжанова) 1931 елнын 18 мартында Татарстан Республикасы Алабуга районы Татар Домдоме авылында туа. Беренче сыйныфны гына тәмамлап олгерә - сугыш башлана. Матур вакытлар - балачак еллары. Кояш, әни елмаюы һәм шатлык белән тулган була шул балачак... Еллар узу белән анда ешрак кайтасы килә һәм бары тик хәзер генә бу бәхетнен нинди бәхет икәнен абайлыйсын - ваемсыз балачак, тыныч кvк астындагы матур балачак. Сугыш башлану белән бергә балачак та бетә. Авыл ир-атларын фронтка алалар, алар урынына хатын-кызлар, картлар һәм балалар баса.

Ун яшьлек Сәймәгә колхоз ишегалдына су ташуны йоклиләр. Кечкенә генә кызга атлар бик зур булып тоелдылар, шуна ул алардан курка да иде. Колхоз аты караучысы куркак кызчыкка арбасына vгез жигәргә кинәш итә. Ә vгезләр - кичәге бозаулар бит инде: ул әнисенә аларны карарга булышкан, кулдан ашаткан. Алар алдында кызчыкта курку булмаган. Авылдашлары, олы колхоз vгезләре белән кечкенә генә Сәймәне кvреп, гажәпкә кала иделәр. Су жыярга, аны алып килергә, аннан vгезләрне жигәргә вакыты да юк иде анын. Нинди уеннар инде ул: су алып кайтканнан сон, ул чыбыкка яки печәнгә йогергән, урып-жыюда катнашкан. Сугыш чоры балачагы: эш егылганчы, ә ризык - бер тамчы. Бер яктан гына аларга бәхет елмайган иде шул вакыт: әтисе Фәттах, шахтада эшләгәнгә, фронтка эләкмәгән. Ә кvршеләре ышаныч һәм курку белән хат ташучыны коткәннәр: әтисеннән, иреннән, абыйсыннан шатлыклы хат килерме, әллә кvзләрен яшереп кара очпочмакны тапшырырмы хат ташучылары? Әмма барыбыр олы Жинv житте. Бу жинv безнен халыкка нинди югалтулар белән килде! Илебез янадан бик авыр торгызыла, эшче куллар житми һәм унжиде яшьлек Сәймә әтисе хезмәт иткән Кизил шәһәре шахтасына эшкә китә. Бу авыр, ир-ат эше иде, әмма Сәймә Фәттах кызы: «Сугыштан сон жинелрәк, куанычлырак булды», - дип раслый.
Яшь кыз башка якларны да карарга тели. Шулай, 1950 елда ул Пермь олкәсенен Гремячий бистәсенә кvчеп килә һәм анда да башта шахтада эшли. Шахтада ул булачак ире Сәйдәфәр Исмәтулла улы Алыков белән таныша. Бик тыйнак туй уйныйлар. Матур

гына яшәп китәләр, дип искә ала Сәймә Фәттах кызы. Икесе дә тырышып эшли, шуна кvрә гаиләдә бар нәрсә житәрлек була. Тормыш итпәше Сәйдәфәр Ис-мәтулла улы белән дvрт кыз һәм бер ул тәрбияләп vстерәләр. 1969 елда ире туган ягына - Инсар районы Яндовище авылына, гаиләләре белән кvчеп киләләр. Ире колхозга тракторчы, ә Сәймә Фәттах кызы сыер савучы булып урнашалар. Тормыш vз чираты белән бара башлый. Балалар vсеп житә, гаилә коралар, оныклары туа.
Тормыш бит ул бер ак, бер карадан тора. Аларга да кара кайгы килә: ике оныклары ятим кала. Сәймә әби белән Сәйдәфәр бабай бер секунд та икеләнми: оныклары алар белән яшәячәкләр. Һәм алар балаларны аякка бастырдылар, онықчык- ларын да кvтәрергә кочләре житкән.
Саймә Фаттах кызы пенсиягә кадәр сыер савучы, аннары, пенсиядән сон авыл Советында һәм мәктәптә техник хезмәткәр булып эшли. Ире 1992 елда вафат бу-ла. Ул бу хәсрәтне нык кичерә, әмма оныклары янәшәсендә иде, балачак- ларын ямьсезләргә ярамый иде. Шулай язмыш куша. Оныклары vсеп, гаилә корганнар, балалары туганнар. Әйтеп китәргә кирәк, Сәймә апа гомер буе алар турында кайгыртып яши; якыннарын, туганнарын, соеклеләрен кайгыртып. Ә гомерен тырыш хезмәттә vткәрә. Сәймә Алыкованын берничә бvләкләрен әй-теп китик: бишьеллыкнын беренче елында югары савым очен «Мактау грамотасы» (1976 ел), «Хезмәт ветераны» медале (1981 ел), «Социалистик ярыш жинvчесе» медале (1975 ел) һәм (1976 ел), «9 бишьеллык ударнигы» медале (1976 ел), «Сугыш чоры балалары» медале (1976 ел). Менә шундый ул Сәймә әбинен язмышы. Нәрсәләр белән горурланасыз дигән сорауга бераз уйланып торды, ә аннан йозендә бәхетле елмаю балкыды. Сәймә апа:
- Балаларым һәм оныкларым белән горурланам! Минем 12 оныгым, 19 онықчыгым бар.
Кечкенә Сәймәнен балачагы юк иде - сугыш аны тартып алса да, анын бәгыре, жаны катмады; балалары, оныклары һәм онықчыклары яратуы һәм кайгыртучынлыгы жылытты.

Н.ХӘЛИЛ